**Казан шәһәре Башкарма комитетының
2024 елның 27 августындагы 3581 номерлы карары**

**«“Алтын мөнбәр” XX Казан халыкара кинофестивале» чарасын әзерләү һәм уздыру чорында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуныны вакытлыча чикләү турында**

«Алтын мөнбәр» XX Казан халыкара кинофестивален әзерләү һәм уздыру максатыннан, шулай ук 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буенча транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә:

1. **Карар бирәм**:

1.1. Пушкин урамының Карл Маркс урамыннан алып Большая Красная урамына кадәрге участогында 2024 елның 6 сентябрендә 15:00 сәгатьтән 21:00 сәгатькә кадәр транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуныны вакытлыча чикләүне билгеләргә;

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.2.1. транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуныны вакытлыча чикләү чорында вакытлы юл билгеләрен урнаштыру схемасын эшләргә һәм вакытлы юл билгеләрен урнаштыру һәм эшләп килүче юл билгеләрен каплау буенча чаралар оештырырга;

1.2.2. транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуныны вакытлыча чикләү турында мәгълүматны Интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырырга;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (И.И.Сәлахетдинов) Казан шәһәре Башкарма комитетының

Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе белән берлектә (А.И.Салихов) йөк техникасы яисә таранга каршы блоклар белән юлларны ябу эшен оештырырга;

1.4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсенә (А.И.Абзалов) чараны әзерләүдә һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтергә;

1.5. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**2. Тәкъдим итәм:**

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Н.Д.Закиров) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участогында юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) күрсәтелгән урам-юл челтәре участогында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөклим.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**